**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле  авыл җирлеге Кизләү авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында КАРАР**

«07» ноябрь  2023 ел                                                                                    № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2023 елның 7 ноябрендә узган: «Киекле авыл җирлегенең Кизләү авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм яшәүче, 1 гр инвалидлардан, балачактан инвалид булганнарның,  Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган хатыннарыннан, СВОда катнашучылардан кала, балигъ булган һәр кешедән 2024 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган  акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм эчәр су белән тәэмин итү максатыннан халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;

- Кизләү торак пункты чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту, шул исәптән таш, суккан кирпеч, туфрак, вак таш, ком, асфальт ватыклары (сатып алу, ташу, салу), чокыр ремонтлау (коелган асфальт);

- Кизләү торак пунктында урамнарны яктыртуны оештыруны тәэмин итү өчен товарлар (эшләр, хезмәтләр) төзү, сатып алу;

- Кизләү торак пунктында янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү;

- җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне)төзекләндерү;

- ремонт, коймалар төзү, Кизләү торак пунктында традицион җирләү урыннарын карап тоту;

халыкның күпләп ял итү урыннарын (парклар, спорт мәйданчыклары, балалар мәйданчыклары һәм халыкның башка күпләп ял итү урыннарын) төзү, ремонтлау, товарлар (эшләр, хезмәтләр) сатып алу һәм аларга якын территорияне төзекләндерү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча  беркетмә төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:
җыенда катнашучы  сайлау хокукына ия булган гражданнар исемлегенә 373 кеше кертелгән, җыенда тавыш бирүдә 221 кеше катнашты.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«ӘЙЕ» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 196 кеше тавыш бирде;
«ЮК» позициясе өчен җыенның 25 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле  авыл җирлеге Кизләү авылы торак пунктында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.
2. «Киекле авыл җирлегенең Кизләү авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм яшәүче, 1 гр инвалидлардан, балачактан инвалид булганнарның,  Бөек

Ватан сугышында катнашучыларның тол калган хатыннарыннан, СВОда катнашучылардан кала, балигъ булган һәр кешедән 2024 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм эчәр су белән тәэмин итү максатыннан халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;

- Кизләү торак пункты чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту, шул исәптән таш, суккан кирпеч, туфрак, вак таш, ком, асфальт ватыклары (сатып алу, ташу, салу), чокыр ремонтлау (коелган асфальт);

- Кизләү торак пунктында урамнарны яктыртуны оештыруны тәэмин итү өчен товарлар (эшләр, хезмәтләр) төзү, сатып алу;

- Кизләү торак пунктында янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү;

- җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне)төзекләндерү;

- ремонт, коймалар төзү, Кизләү торак пунктында традицион җирләү урыннарын карап тоту;

халыкның күпләп ял итү урыннарын (парклар, спорт мәйданчыклары, балалар мәйданчыклары һәм халыкның башка күпләп ял итү урыннарын) төзү, ремонтлау, товарлар (эшләр, хезмәтләр) сатып алу һәм аларга якын территорияне төзекләндерү мәсьәләсе буенча кабул ителгән карарны танырга.

3. Халык җыены нәтиҗәләрен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда, Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Киекле авыл җирлеге Кизләү авылы мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле авыл җирлеге тарафыннан кабул ителгән әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче: Л.И. Кашапова

Киекле авыл җирлеге башлыгы: Л.И. Кашапова